**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » июль 2019 ел № 206

«Геология» АЖ Чәкән нефть ятмалары
№40304 скважиналар куагын төзекләндерү» проекты
составында Азнакай муниципаль районы Югары
Стәрле, Вахит, һәм Урманай авыл җирлекләре
чикләрендә территорияне планлаштыру `һәм межалау
проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Азнакай муниципаль районында ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып, **карар бирәм:**

1. «Геология» АЖ Чәкән нефть ятмалары №40304 скважиналар куагын төзекләндерү» проекты составында Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле, Вахит, һәм Урманай авыл җирлекләре чикләрендә территорияне планлаштыру `һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2.Ачык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты — 2019 елның 5 июленнән 2019 елның 6 августына,8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Азнакай ш., Ленин ур., 22 йорт;
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 6 августына кадәр - Азнакай шәһәре, М. Солтангалиев урамы, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә, төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) кертелә ала.

4. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына:

- «Геология» АЖ Чәкән нефть ятмалары №40304 скважиналар куагын төзекләндерү» проекты составында Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле, Вахит, һәм Урманай авыл җирлекләре чикләрендә территорияне планлаштыру `һәм межалау проекты буенча ачык тыңлауларны, гамәлдәге законнар һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда,әзерләргә һәм уздырырга.

5. Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру һәм территорияне межалау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын, кушымта нигезендә, расларга

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru..

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
район Башлыгы карарына №1 кушымта
« ___ »________2019 года №__ ____

«Геология» АҖ Чәкән нефть ятмалары
№40304 скважиналар куагын төзекләндерү» проекты составында Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле, Вахит, һәм Урманай авыл җирлекләре чикләрендә территорияне планлаштыру `һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләүче комиссия составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Аюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанова Л. С. | Азнакай муниципаль районы Вернестярлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Бухарова И.Б. | Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Закиров А.И. | Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |